**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе турында» Указына һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турында үтенечнамәләрне карау хакында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе турында» 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-873 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 12 августындагы ПУ-684 номерлы һәм 2020 елның 16 апрелендәге ПУ-232 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе турында нигезләмәнең 2 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 6 пунктның «б» пунктчасында «буенча» сүзеннән соң «оешманың» сүзен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 9 һәм 10 пунктлар өстәргә:

«9. Гражданның салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы турында белешмә.

10. Гражданның фамилиясен, исемен, атасының исемен алмаштыру фактын раслаучы документлар (андый үзгәрешләр булган очракта).».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турында үтенечнамәләрне карау хакында» 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-875 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 12 августындагы ПУ-684 номерлы һәм 2020 елның 16 апрелендәге ПУ-231 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибенең 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 5 пунктның «б» пунктчасында «буенча» сүзеннән соң «оешманың» сүзен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 13 һәм 14 пунктлар өстәргә:

«13. Гражданның салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы турында белешмә.

14. Гражданның фамилиясен, исемен, атасының исемен алмаштыру фактын раслаучы документлар (андый үзгәрешләр булган очракта).».

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 11 август
№ ПУ-475